## 15. Җәй

Хыялга күмеп күңелне
Җәй алды кочагына.
Күпме якты өстәр тагын
Балачак учагына.
Кушымта: Чәчләрдән таң җиле сыйпый,
Йөзләр - кояш нурында.
Иртән җырчы сандугачлар
Коена чык суында.
Печән исе җанга сеңгән,
Җиләк тәме - ирендә.
Без - шаяннар, бәхетлеләр
Җәйге хыял илендә.
Кушымта.
Яшен яшьнәп, күк күкрәсен,
Дөньяның гүзәл чагы.
Кырларда алтын хәзинә -
Офыклар якты сары.